СОВЕТ ВЕРХНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с..Верхняя Ошма, д.54 а, с. Верхняя Ошма, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422163

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ УШМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., №54а нче йорт,ЮгарыУшма авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422163

тел.(факс): (85563) 2-32-36; e-mail: Voshm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Карар
22 июнь 2022 ел　　　　　　　　　　　　　　　　　№2-16

Югары Ушма авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмә, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Югары Ушма авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә, кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында төзелгән килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советының 2021 елнын 12 ноябрендәге 13-9 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында нигезләмә»не үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советының 2016 елнын 3 мартындагы 1-6 номерлы карары белән расланган «Мамадыш муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренә аттестация үткәрү турында нигезләмә»не үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Югары Ушма авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /И.З.Исмагилов/